**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның «12» апреленнән** **№ 35-200**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 14 декабрендәге 31-182 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 июлендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 гыйнварындагы 39 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 14 декабрендәге 31-182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары»на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.6 пунктында «үткәргәндә» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышулар яки» сүзләрен өстәргә;
- 4 нче бүлекнең 4.1.1 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Проектлаганда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы указларына, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына таянып эш итәргә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт программаларындагы, муниципаль программалардагы, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренең социаль-икътисадый үсеше стратегияләрендәге тәкъдимнәрне исәпкә алырга кирәк.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башлыгы** **В. М. Козлов**